ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.02.2021**

.Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№141**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалар тәрбияләүче гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү тәртибен унификацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең 1.3 пунктына үзгәреш кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Гаиләнең җан башына уртача керем компенсация алу хокукын билгеләгәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 20 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган, балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең бер кешегә уртача исәпләнгән керемен исәпләү тәртибенә үзгәрешләр

кертү турында» 1174 номерлы карары белән кабул ителгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең 2.1 пунктындагы «г» пунктчасына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) мөрәҗәгать итүче ананың, атаның (законлы вәкиленең) башка булган балаларының туу (балалыкка алу) турында таныклыкның күчермәләре (күчермәсе нотариаль таныкланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп) ».

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган, Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең 2.1 пунктындагы «б» пунктчасына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) өстәмә компенсация бирү турында гариза биргән айга кадәр алты ай эчендәге гаиләнең һәр әгъзасының керемнәре турында документлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә».

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 01 октябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2220 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев